КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 30 ноябрь г.Казань № 927

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 ел, 31 май, 372 нче карары белән расланган Төбәк әһәмиятендәге яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 ел, 31 май, 372 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 27 февраль, 115 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төбәк әһәмиятендәге яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

19 нчы пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«каты коммуналь көнкүреш калдыкларын җыю һәм транспортлау өчен файдаланыла торган махсуслаштырылган транспорт чараларына (чүп ташый торган машиналарга).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\927.docx